**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ БОГАДЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕСОВЕТЫ**

423763, Иске Богадыа вылы, Үзәк ур.,
60нчыйорт.
Тел.:(85552)5-45-30; факс:5-45-30;
E-mail: sbuq-akt@yandex.ru

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ СТАРОБУГАДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА**

423763, село Старые Бугады,
ул. Центральная, дом 60.
Тел.:(85552)5-45-30; факс:5-45-30;
E-mail: sbuq-akt@yandex.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**“26”ноябрь 2024 ел.** **№3**

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Богады авыл җирлеге составына керүче Иске Солтангол авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районының Иске Богады авыл җирлегенең Иске Солтангол авылында 2024 елның 26 ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.:

«Яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданнан, җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдергән мөнәсәбәтләренә карамастан, 2025 елда үзара салым түләүне бер тапкыр 500 (биш йөз) сум күләмендә кертүгә ризамы сез? Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация кысаларында мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Украинадагы махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләрдән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артмаска тиеш һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне, түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлтеп:

1.Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә (су белән тәэмин итүне карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү,Иске Солтангол авылы суын тикшерү).
2.Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру

өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Иске Солтангол авылы урамнарын яктыртуны карап тоту һәм ремонтлау).
3.Торак пункт территориясен төзекләндерү ( Иске Солтангол авылы территориясендә агачлар кисү ).
4.Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау, ПГС салу, грейдерлау, кардан чистарту,Иске Солтангол авылы кырыйларын чаптыру ).
5. Ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (Иске Солтангол авылы зиратларын карап тоту).
6.Һәйкәлләр төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Иске Солтангол авылы һәйкәлләрен һәм обелискларын ремонтлау).
7.Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (контейнерлар сатып алу, Иске Солтангол авылында рөхсәтсез чүплекләрне бетерү).

«Риза» "Каршы" «Тыелып калдылар»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 63 граждан, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 41 граждан кертелде.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Риза» -41 граждан тавыш бирде;
«Каршы»- 0 граждан тавыш бирде.
«Тыелып калдылар»-0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Иске Богады авыл җирлегенең Иске Солтангол авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Мәсьәлә буенча карарны танырга:
«Яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданнан, җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдергән мөнәсәбәтләренә карамастан, 2025 елда үзара салым түләүне бер тапкыр 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым түләвен кертүгә ризамы сез? Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация кысаларында мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Украинадагы махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләрдән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артмаска тиеш һәм алынган

акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне,  түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлтергә

3. Әлеге карарны Иске Богады авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында http://aktanysh.tatar.ru урнаштырырга

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Актаныш муниципаль районы Иске Богады
авыл җирлеге Советы Рәисе И.Ф.Фаттахов.